КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 3 август г.Казань № 619

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 6 июль, 561 нче карары белән расланган Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә чараларны тормышка ашыру өлешендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә чараларны тормышка ашыру өлешендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 6 июль, 561 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 18 ноябрь, 1032 нче; 2020 ел, 25 декабрь, 1189 нчы; 2021 ел, 27 апрель, 287 нче; 2021 ел, 13 декабрь, 1213 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә чараларны тормышка ашыру өлешендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктның беренче абзацында «файдалану нәтиҗәләре» сүзләрен «бирү нәтиҗәләре» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма буенча төзелә торган килешү нигезендә бирелә.»;

11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

башка бюджетара трансфертлар күләме, аларның максатчан билгеләнеше;

башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе күрсәткече;

башка бюджетара трансфертларны күчерү тәртибе;

финанслашу максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгымнар турында һәм аларга ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр һәм башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисаплылык тапшыру сроклары һәм формалары;

башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсенә ирешмәү нәтиҗәләре;

муниципаль берәмлек тарафыннан килешүдә каралган башка бюджетара трансфертлар бирү шартларының үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе;

килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен якларның җаваплылыгы.»;

12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәләре күрсәткеченә ирешүне бәяләү Министрлык тарафыннан башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәсенең килешүдә билгеләнгән һәм фактта ирешелгән күрсәткечен чагыштыру нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Муниципаль берәмлекнең башкарма комитетлары Министрлыкка Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган формалар буенча килешүдә каралган срокларда финанслашу максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгымнар турында хисап, башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү һәм аларга ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр турында хисаплар тапшыра.»;

18 пунктта:

унынчы абзацта «файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченең» сүзләрен «бирү нәтиҗәсенең» сүзләренә алмаштырырга;

унберенче абзацта «файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченең» сүзләрен «бирү нәтиҗәсенең» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин